| | |
|---|---|
| СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>«30» сентябрь 2024 ел | **КАРАР**<br>№ 103 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Карадуган авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында " нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Бюджет законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советы карары белән расланган 11.11.2019 елның 122 номерлы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4 статьяның 6 пунктында:

- 10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) алучыларның максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре, аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртибен үтәвен тәэмин итә;»;

- 11 нче пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

- 13 пунктчада «муниципаль район» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга.;

- түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктча өстәргә:

«13.1) иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән “Электрон бюджет" мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары, капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет (Дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) акчалары керә;»;

1.2. 4 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) алучыларның максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет

инвестицияләре, аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртибен үтәвен тәэмин итә»;

1.3. 4 статьяның 9 пунктында:

- 6 пунктчада «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.;

- 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итә;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктлар өстәргә:

"8) бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгели;

9) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев